# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлеге
Степановка торак пунктында 2024 елда гражданнардан
үзара салым кертү турында

**20.11.2023 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ атарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге Степановка торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1.2024 елда Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге Степановка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә,1,2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерү:

1) Степановка торак пунктында һәлак булган сугышчыларга обелиск территориясен төзекләндерү (брусчатка сатып алу һәм салу, килешү буенча эш өчен түләү);

2) Степановка торак пунктында Богдановка урамындагы юлларны ремонтлау (таш сатып алу, ташу, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Әлеге карарны Аю авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (http://menzelinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районының
Аю авыл җирлеге башлыгы ______________ А.М.Галимов
(имза)